ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 07.12.2022 **КАРАР**
1472

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 17 октябрендәге 1346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары турында» 2022 елның 17октябрендәге 1346 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертеп түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән (алга таба-хәрби хезмәткәрләр), шулай ук махсус операция вакытында хәрби бурычын үтәгәндә һәлак булган гражданнарының гаиләләрен, ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түбәндәге түләүләрдән азат итәргә:

– Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында туклану, шулай ук баланы карап торганы һәм караганы өчен;

– Алабуга муниципаль районы башкарма хакимияте органнары карамагындагы мәктәпләрдә, мәктәпкәчә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендәге түгәрәкләр һәм секцияләр өчен.

1.1. 2022 елның 1 ноябреннән гомуми белем бирү муниципаль учреждениеләрендә 1 сыйныфтан 4 сыйныфка кадәр укучы балаларны өстәмә бушлай кайнар ризык белән тукландыруны тәэмин итәргә.

1.2. 2022 елның 1 ноябреннән гомуми белем бирү муниципаль учреждениеләрендә 5 сыйныфтан 11 сыйныфка кадәр укучы балаларны ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән тукландыруны оештырыргаәэмин итәргә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 нояреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Е.Д. Терентьевага йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA
Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович
Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Л.Ф. Нургаянов